СОВЕТ ЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д.9, с. Нижние Яки
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422157

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яңа ур., 9 нче йорт, Түбән Яке авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422157

тел.(факс): (85563) 2-94-38; e-mail: Yak.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

28.03.2023 ел | №2-22

## Мамадыш муниципаль районының Яке авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалана алуны тәэмин итү һәм мәгълүмат исемлекләрен раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Рассмотрев Мамадыш районы прокуроры вазыйфаларын башкаручының 2023 елның 01 февралендәге № 02-08-02-2023 протесты, «Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2022елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советының 2012 елның 01 августындагы 3-19 номерлы карары белән расланган Яке авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү һәм мәгълүмат исемлеге тәртибенә (алга таба- Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Тәртипнең 2.7 пунктын үзгәрешләр кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аларга буйсынган оешмаларның рәсми сайтларыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә. Башка дәүләт органнарының һәм аларга буйсынучы оешмаларның, шулай ук җирле үзидарә органнарының һәм аларга буйсынучы оешмаларның рәсми сайтларыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм

лингвистик чараларына таләпләр үз вәкаләтләре чикләрендә күрсәтелгән органнар тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Яке авыл җирлеге башлыгы Р.К. Низамутдиновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районының Яке авыл
җирлеге башлыгы, Совет рәисе Р.К. Низамутдинов